
Корбан бәйрәме алдыннан Дубенка районы Ломат мәчетендә балалар очен жәйге дәресләр тәмамланды. Быел дәресләргә торле яшьтәге 25 бала йорде. Барысы турында авыл имамы Раиль хәзрәт Мусин сойләп бирде:
- Россиянен башка олкәләреннән, шулай ук каникулга килгән Йеменнән балаларны дәресләрдә кvрv минем очен бик кvнелле булды. Укучылар белән бергә без кон саен зарядка ясадык, уеннар уйнадык, мультфильмнар карадык, ә безнен дәресләрнен ин мoһим вакыйгасы - Штырма елгасына сәяхәт булды; суда балалар йозде һәм алар очен әзерләнгән уханы ашый алдылар.      Безнен бәйрәм коннәребез ахырында, Корбан бәйрәме унаеннан, без укучылар очен бәйрәм сюрпризы оештырырга булдык. Укучыларым һәм Ломаттагы барлык балалар очен батутларга заказ бирдек. Бушлай батутлар һәм татлы мамык укучыларыбызны һәм аларнын эти-әниләрен шаккатырды. Безнен мондый чараларыбыз сый-хормәтсез уза алмый, шуна кvрә без Үзбәкстаннан милли пылау әзерләv очен пешекчебезне чакырдык. Аннары Ломат халкы очен бәйрәм салюты булдырдык.
Барлык балалар да бу бvләктән бик канәгать калдылар. Алар безнен киләчәгебез, эшләгән эшләребез аларнын хәтеренә уелып калачак һәм болар барысы да безнен гореф-гадәтләребезне дәвам итv очен хезмәт итәчәк.